**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Чит ил федератив дәүләтләре субъектларында яисә чит ил дәүләтләренең административ-территориаль берәмлекләрендә, чит ил дәүләтләрендә Татарстан Республикасы вәкилләре хезмәте өчен түләү шартлары турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

Чит ил федератив дәүләтләре субъектларында яисә чит ил дәүләтләренең административ-территориаль берәмлекләрендә, чит ил дәүләтләрендә Татарстан Республикасы вәкилләре хезмәте өчен түләүне камилләштерү максатларында, «Татарстан Республикасы дәүләт хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Чит ил федератив дәүләтләре субъектларында яисә чит ил дәүләтләренең административ-территориаль берәмлекләрендә, чит ил дәүләтләрендә Татарстан Республикасы вәкилләре хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2006 елның 25 декабрендәге ПУ-583 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2008 елның 28 гыйнварындагы ПУ-33 номерлы, 2009 елның 17 ноябрендәге ПУ-612 номерлы һәм 2013 елның 29 октябрендәге ПУ-1046 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 1 пунктның «б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына туры килгән айлык окладлар, аларга бирелгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте класслы чиннарына туры килгән айлык окладлар, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында һәм «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең акчалата гомуми хезмәт хакы турында» 2018 елның 22 мартындагы ПУ-239 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указында каралган айлык һәм башка өстәмә түләүләр (монда айлык акчалата бүләкләү керми), рубльләрдә 16,5 процент күләмендә (алга таба – рубльләрдә түләүләр).»;

б) түбәндәге эчтәлекле $3^1$ пункты өстәргә:

«$3^1$. Әлеге Указның 1 пункты «б» пунктчасында күрсәтелгән рубльләрдә түләүләр күләме арттыру ягына бөтен бер сумга кадәр түгәрәкләнергә тиеш, дип билгеләргә.»;

в) 4 пунктта «2006 елның 5 апрелендәге ПУ-133 номерлы Указы» сүзләрен «2018 елның 22 мартындагы ПУ-239 номерлы Указы» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына әлеге Указны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны билгеләнгән тәртиптә финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге Указ рәсми басылып чыккан көннән 10 көн узгач үз көченә керә һәм 2018 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2018 ел, 22 март
№ ПУ-241